**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР**
**17 апрель 2019 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 293**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр Исемлеген раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 ел, 6 нчы октябрь 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 ел, 27 нче июль, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы 1 бүлеге 3 бүлекчәсе, Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр Исемлеген расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Биектау муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр Исемлеген раслау турында” 2017 ел, 30 нчы март, 130 номерлы карарын;

- Биектау муниципаль районы Советының “Биектау муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр Исемлеген раслау турында” 2017 ел, 30 нчы март, 130 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” 2017 ел, 26 нчы май, 149 номерлы карарын;

- Биектау муниципаль районы Советының “Биектау муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр Исемлеген раслау турында” 2017 ел, 30 нчы март, 130 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” 2018 ел, 28 нче март, 207 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин

Кушымта

Расланган
ТР Биектау муниципаль районы
Советы карары белән
17.04. 2019 № 293

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛӘ ТОРГАН МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘР ИСЕМЛЕГЕ**

| № т/б | Муниципаль хезмәт исеме |
|---|---|
| 1. | Торак бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү (килештермәү) турында карар кабул итү |
| 2. | Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә яки сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану |
| 3. | Торак булган (торак булмаган) бинаны торак булмаганга (торак булган) күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү |
| 4. | Төзелеш алып баруга рөхсәт бирү |
| 5. | Шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йортының параметрлары белдерү кәгазендә күрсәтелгән планлаштырылган төзелеш параметрларына, җир кишәрелегендә шәхси торак төзелеше яки бакча өен урнаштыру өчен билгеләнгән параметрларга һәм рөхсәт ителгән (рөхсәт ителмәгән) туры килүе турында (туры килмәве турында) белдерү кәгазе җибәрү |
| 6. | Объектны кулланылышка тапшыру буенча рөхсәт бирү |
| 7. | Төзелгән яки төзекләндерелгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазьләре җибәрү |
| 8. | Капиталь төзелеш объектлары төзелешендә, төзекләндерүендә рөхсәт ителгән чик буе параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү |
| 9. | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү |
| 10. | Инженер челтәрләре трассалары һәм коммуникацияләре схемаларын килештерү |

| | |
|---|---|
| 11. | Ана (гаилә) капиталы чараларын җәлеп итеп тормышка ашырыла торган шәхси торак төзелеше объектлары төзелеше (төзекләндерү) буенча төп эшләрне уздыруны раслаучы документны бирү |
| 12. | Җир кишәрлеген шартлы рәвештә куллану төрен куллануга рөхсәт бирү турында карар кабул итү |
| 13. | Җирлекнең Генераль планыннан өземтә бирү |
| 14. | Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүче эшчәнлек мәгълүмат системасындагы мәгълүматларны бирү |
| 15. | Җир эшләре башкару өчен ордер (рөхсәт) бирү |
| 16. | Җир кишәрлеген бирүне алдан килешетереп кую |
| 17. | Территорияләрнең кадастр планында җир кишәрлегенең яки җир кишәрлекләренең урнашу схемасын раслау |
| 18. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү |
| 19. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген хосусый милеккә бушка бирү |
| 20. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген түләүсез кулланылышка бирү |
| 21. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сату |
| 22. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген торглар үткәрмичә арендага бирү |
| 23. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген торглар үткәрмичә, әлеге җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма милке ияләренә хосусый милеккә яки арендага бирү |
| 24. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген аукцион формасында уздырыла торган торгларда арендага бирү |
| 25. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген аукцион формасында уздырыла торган торгларда сату юлы белән хосусый милеккә бирү |
| 26. | Дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен, шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен һәм (яки) җирләрне яңадан бүлү турында шартнамәләр төзү |
| 27. | Муниципаль милектә булган җирләрне яки җир кишәрлекләрен куллануга рөхсәтләр бирү |

| | |
|---|---|
| 28. | Аерым максатларда халык алдында сервитутлар урнаштыру |
| 29. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданнарга яки крестьян (фермерлык) хуҗалыкларына крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан үз эшчәнлеген тормышка ашыру өчен хосусый милеккә (арендага) бирү |
| 30. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданнарга торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен хосусый милеккә (арендага) бирү |
| 31. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданнарга бакчачылык алып бару өчен хосусый милеккә (арендага) бирү |
| 32. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданнарга дача хуҗалыгы алып бару өчен хосусый милеккә (арендага) бирү |
| 33. | Шәхси яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген бер категория җирләр составыннан икенчесенә күчерү (авыл хуҗалыгы өчен җирләрдән кала) турында карар кабул итү |
| 34. | Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яки җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату |
| 35. | Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү |
| 36. | Җир кишәрлеген арендага бирү шартнамәсенә үзгәрешләр кертү |
| 37. | Җир кишәрлекләрен бушлай бирүгә хокуклары булган затлар сыйфатында исәпкә кую |
| 38. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлекләре мөнәсәбәтендә сервитутлар урнаштыру турында килешүләрне төзү |
| 39. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген шәхси торак төзелеше өчен гражданнарга хосусый милеккә (арендага) бирү |
| 40. | Муниципаль торак фонды торак биналарын гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү |
| 41. | Элек приватизацияләнгән торак биналарны муниципаль милеккә кабул итү |
| 42. | Муниципаль милекне муниципаль учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык итү хокукында рәсмиләштерү (беркетү) |
| 43. | Муниципаль милек реестрыннан өземтәләр бирү |

| | |
|---|---|
| 44. | Муниципаль милектә булган һәм арендага бирелергә тиешле күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат тәкъдим итү |
| 45. | Муниципаль казнаны тәшкил итүче милекне арендага бирү |
| 46. | Муниципаль милек реестрына керүче муниципаль милекне арендага бирү |
| 47. | Муниципаль милекнең муниципаль милкен торглар уздырмыйча гына түләүсез куллануга тапшыру |
| 48. | Муниципаль милек белән түләүсез куллану шартнамәсен әлеге шартнамә төзү хокукы бирүче торглар нәтиҗәләре буенча төзү |
| 49. | Муниципаль милекнең гамәлдә булган арендага бирү шартнамәсен бетерү |
| 50. | Реклама конструкциясен куюга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү |
| 51. | Муниципаль милектә булган өстәге су объектын, яки аның өлешен куллануга бирү турында рөхсәт бирү |
| 52. | Товарлар, эшләр хезмәтләр житештерүче юридик затларга (дәүләт (муниципаль учреждениеләргә бирелә торган субсидияләрдән кала), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга субсидияләр бирү |
| 53. | Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү |
| 54. | Муниципаль берәмлек чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар буйлап тулысынча яки өлешчә уза торган маршрутлар буенча автомобильләр белән эре габаритлы йөкләр, авыр йөкләр ташуга рөхсәт бирү |
| 55. | Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юллары торышы турында мәгълүмат бирү |
| 56. | Муниципаль преференцияләр бирү |
| 57. | Муниципаль милекне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына хуҗа булуга һәм (яки) файдалануга бирү |
| 58. | Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ булган гражданнарны исәпкә алу |
| 59. | Муниципаль торак фондыннан хезмәт урынына караган торак урынына найм шартнамәләре буенча торак урыннарны гражданнарга бирү |
| 60. | Социаль найм шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарны алмаштыру буенча документлар рәсмиләштерү |

| | |
|---|---|
| 61. | Муниципаль торак фондындагы торак бинаны социаль найм шартнамәсе буенча гражданга бирү |
| 62. | Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую |
| 63. | Авыл җирлегендә яшәүче гражданнарга торак төзүгә (алуга) социаль түләүләр бирү, шул исәптән яшь гаиләләргә һәм яшь белгечләргә |
| 64. | "2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү" ярдәмче программасы буенча торак алуга (төзүгә) социаль түләүләр алуга хокук бирү шаһәдәтнамәсен бирү һәм исәпкә кую |
| 65. | Торак урыннарга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую |
| 66. | Чернобыль АЭСындагы һәлакәт һәм «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга һәм аларга тиңләштерелгән затларга Дәүләт торак сертификатын бирү һәм исәпкә кую |
| 67. | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар сыйфатында исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алуга субсидия бирү өчен Дәүләт торак сертификатын бирү |
| 68. | Архив белешмәләрен, архив өземтәләрен, архив документлары күчермәләрен бирү |
| 69. | Дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта саклаучы архив фондлары буенча архив белешмәләрен, архив өземтәләрен, архив документлары күчермәләрен бирү |